**Республика Татарстан**
**Глава Большенуркеевского сельского поселения Сармановского муниципального района**

Ул. Школьная, д. 32, с. Большое Нуркеево Сармановский район, 423372

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Зур Нөркәй авыл җирлеге башлыгы**

Мәктәп урамы, 32 нче йорт, Зур Нөркәй авылы, Сарман районы, 423372

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28 октября 2019 г. № 4

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Зур Нөркәй авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2019 елның 13 ноябренә 14 сәгатьтә Сарман муниципаль районының «Зур Нөркәй урта мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җыелышын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга: “2020 елда Зур Нөркәй авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку йортлары студентларыннан, дүрт һәм аннан да күбрәк балалы гаиләләрдән тыш, 200 сум узара салым җыярга һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларның түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтелүе белән килешәсезме:

- Зур Нөркәйдә (Сабантуй, 9 Май, өлкәннәр көне, Инвалидлар көне) бәйрәмнәрне үткәрү өчен бүләкләр алу;

- махсуслаштырылган техниканы карап тоту – “Беларус-82.1” тракторы (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машина йөртүчегә хезмәт күрсәтү өчен түләү);

- Зур Нөркәй авылы Болын урамында яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру;

- Зур Нөркәй авылының Болын урамында 300 м озынлыкта вак таш түшәмәсен (вак таш ташу) ремонтлау;

- Зур Нөркәй авылы территориясендә көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарны вакытлыча җыю урыннарын җыештыру;

- район "Сарман" газетасында некрологларны бастырып чыгару»

«ӘЙЕ» ЮК".

3.Зур Нөркәй авыл җирлеге Башкарма Комитетына халык җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

4. «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Зур Нөркәй авылы торак пункты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

5. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам

ТР Сарман муниципаль районы
Зур Нөркәй авыл җирлеге башлыгы Р.М. Гайсин